Reviews

Бәяләмә һәм күзәтүләр

Рецензии и обзоры

DOI: 10.26907/2311-2042-2023-21-2-179-188

# REVIEW OF THE POPULAR SCIENCE COLLECTION "АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ" (COMP. KHABUTDINOVA M. M. KAZAN: JYEN, 2023. 672 B.)

**Gulfia Rasilovna Gaynullina,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
gulfiarasilevna@mail.ru.

The purpose of the article is to review the popular science collection called "Аяз Гыйләҗев" ("Ayaz Gilyazov") (comp. by M. M. Khabutdinova - Kazan: Jyen, 2023. 672 p.). The collection includes memoirs about Ayaz Gilyazov (1928–2002), the People's Writer of the Republic of Tatarstan, winner of the State Prize named after G. Tukay, as well as the author's autobiographical works, critical and journalistic articles, interviews, photographs and documents from the writer's personal archive.

The diaries and documents stored in the personal archive of the writer and publicist Ayaz Gilyazov, a classic of Tatar literature, a prominent representative of Tatar prose of the second half of the 20th century, have been collected and presented to the scientific community by Candidate of Philology Milyeusha Khabutdinova, a literary scholar who compiled a collection of reviews, which are of great significance in the studies devoted to the development of social consciousness in the 20th century. The publication is based on the principles of chronological and genre diversity. The material is subsumed into eight sections. The last section, entitled "Татар кодексы" ("The Tatar Codex"), has a quote from Rafael Sibat's review of Ayaz Gilyazov's work "Йәгез, бер дога!" ("Let's Pray!"). The writer's contribution to the national literary art and methods of research along with the methods for analyzing and the scientific principles of evaluation of his works are highlighted in the preface to Milyeusha Khabutdinova's collection and in her articles about the writer's letters and diaries, as well as in the memoirs of M. Sh. Shaimiev, the First President of the Republic of Tatarstan and State Adviser, the scholar I. Andreeva, the writers G. Akhunov, R. Zaidulla, Sh. Rakipov, R. Valiyev, A. Litvin, M. Galiev, T. Galiullin and R. Mukhamadeev.

**Key words**: Tatar literature, literature, literary criticism, memoirs, diaries, A. Gilyazov

Ayaz Gilyazov (1928–2002) was a People's Writer of Tatarstan, laureate of the Tatar ASSR State Prize named after G. Tukay and the RSFSR State Prize named after M. Gorky, literary prizes of the Union of Writers of Tatarstan named after G. Iskhaki and S. Rafikov and an Honored Artist of

Tatarstan and Russia. His literary and journalistic work has always been the focus of Tatar literary criticism. The literary critic Milyeusha Khabutdinova has made an invaluable contribution to the study of the writer's multi-layered oeuvre for over the past three decades and his popularization on the world literary arena. She has prepared for publication the collection of literary criticism on his works of different eras and the conceptual assessment of his classical creative work. The scholar compiled a new academic six -volume book of the writer based on the personal archive of Ayaz Gilyazov [1] whose literary heritage has been published in Russian, English, Turkish, Hungarian and Khakass languages [2]. His dramatic works were performed on the stages of theatres in some Turkic-speaking countries [3], [4]. The scholar published many articles, highlighting the contribution of the Tatar writer to the development of world literature [5] – [26]. Having established contacts with world-famous art people with whom the writer was in touch, M. Khabutdinova familiarized the Tatar literary and cultural community with the Hungarian writer Arpad Galgotsi. Many politicians and numerous representatives of the intellectuals described the writer's family in their memoirs and spoke about him in the academic community.

Addressing her reader in the introduction, M. Khabutdinova clearly states the purpose of creating the collection: "A. Gilyazov is not only a talented writer, but also a conscientious figure of our nation. Dear reader! While holding this book in your hands, try to remember the writer who made a great contribution to the literary heritage of the Tatars, respect him and enjoy reading his books!" [28, p. 5].

The collection starts with Ayaz Gilyazov's autobiographical notes. The writer's nine articles, written between 1972 and 2000, are presented here. In his first work of 1972, "Үзем турында үзем" ("Me About Myself), he describes his literary work as simply as that: "Devotion to one's Homeland and the people, an infinite love for the native language – these are the solid beacons of any writer! Even though our living conditions and life phenomena change from day to day, these great concepts are eternal and only people who are faithful to this eternity can undergo changes together with their people" [28, p. 5]. The chapter "Үзем" ("Myself") from the short story "Яра" ("The Wound") written between 1984 and 1989 - the poem that concludes the first chapter in the collection - is placed here to demonstrate the writer's commitment to his chosen beacon: "Eternity is our holy land, our blue planet. Eternity is our blue sky, the eternally shining sun, the Moon with its soft and gentle light, countless stars that adorn our life and make it festive. It is our Volga, our winding beautiful language, our melancholy, Tukay, Saydash... Beethoven, Chaliapin and Grieg can easily reach our souls; there is room for oceans, seas, rivers and Caucasian-Crimean Mountains too; they also belong to you, you are a human being, your soul can wish for and absorb a lot. They say "the spirit", they say "the heart", and the Tatar people place in the center of these words a mysterious sea called "Kung'el" (the Soul). The human Soul is invisible and impossible to feel, but it does exist. The soul is born and created together with a person; it is empty in the beginning, but becomes gradually enriched with life experience, feelings, impressions and love) [28, p. 138].

Ayaz Gilyazov sees Tatar literature as an integral part of world literature and sees creative heritage as a gem that can promote the nation in the world. Scholar Milyeusha Khabutdinova presents the material in the collection based on that concept.

The second chapter contains the writer's letters. In the article "Хат – сәнгатьнең бер төре ул" ("A letter is one of the types of art"), given in the introduction to the section, the scholar emphasizes how important the letter-writing was to the writer: "He often asked his close family and friends to collect his letters, but for various reasons, many of them have been lost. And those that have been collected help us study his autobiography and grasp the political and social events typical of that period" [28, p. 144]. It is noteworthy that M. Khabutdinova later pointed out that A. Gilyazov's mental state changed to a depressive one. This conclusion is based on the writer's own words when he moved away from letters taking up the genre of diaries: "In ninety-two (1992), I cut back on letters, there were no people left with whom I could share feelings, thoughts and solve mysteries. I took my thoughts to the lonely alley and hid them in the dark lake called "diaries") [28, p. 147].

More than two dozen letters are addressed to Prof. Nakiya Gimadieva-Gilyazova, the writer's beloved wife who was faithful to her family and her husband's chosen path; to free thinkers, his fellow writers Amirkhan Yeniki, Muhammad Magdeev, Tufan Minnullin, Shaukat Galiev, Yakud Zankiev and Nazip Assanbayev, to the editorial office of the newspaper "Kazan Utlary", translator Iskander Gizzatullin, critic Mansur Valiev and other patriots. The letters convey the writer's emotional grief and his worries about the

nation, as well as his critical remarks concerning the literary and cultural process of that time. To explain the principle of combining letters into one set, one should just quote an excerpt from the writer's letter addressed to M. Valiev in 1982: "From now on, how many literary gems shall we have left behind, those on a par with Tukay, Taktash and Dzhalil? Indeed, the future will decide the fate of books and evaluate the power of new writers, but this interpretation of the state of things does not give us the right to go back on our demands. On the contrary, we must always be on guard and strive to support the development of our literature. However, we have relaxed and lowered the criteria a lot recently; we try to put alongside our great literary heritage a lot of works that clearly will not stand the test of time. Now, we have F. Husni and G. Minsky as classics, and we are handing out to random people our only award named after the great citizen G. Tukay, proudly sticking colorful ribbons on it." [28, pp. 208–209]. We should note here that a complete analysis of this field of literary heritage is given in M. Khabutdinova's research works on the analysis of the writer's letters.

The third section holds excerpts from A. Gilyazov's diaries. In the preface to the section "Уйларның төрмәсеннән котылу" ("The liberation from the prison of thoughts") M. Khabutdinova writes: "In 1992–1997, keeping a diary became A. Gilyazov's important duty, a valuable personal act. Later, due to his illness, the writer was unable to keep diaries on his own and this work became too challenging" [28, pp. 208–200]. In the opening part of the section, there is an article by A. Gilyazov "Мин шулай уйлыйм ("I think so"), written in 1980 and published in 2005. Here, the author mentions his concerns about the literary process of the 1960s and 1980s and reveals the motives of the Tatar intellectuals, which took a position of wide recognition of the Tatar literature. He reveals the desire of the literary society of that time to destroy the spirit of genuine patriotism: "Just when we thought that all was lost, Moscow came to our rescue. Moscow Russians and Moscow Jews noticed us and gave us strength and enthusiasm to move forward" [28, p. 343].

In the center of attention is the writer, who considered himself "to be obliged to fight for the people of the Earth", [28, p. 352] showing his concerns for the future of literature and culture in the society that developed in the nineties, while observing declining spiritual values of Tatar writers.

The fourth chapter of the collection has eight critical reviews by Ayaz Gilyazov. It includes a critical review on the works of his contemporaries, based on the principle of "seeing into the people's souls" literature. Tatar literature, without any doubt, should and will receive a worldwide recognition: "Literature, among other goals, brings different peoples closer to each other, introduces them to each other, fosters friendship and kinship in them. This is one of its most sacred duties. I should say, one of the greatest duties. The power of literature in this field is limitless. Literature, the word of poets and writers, goes through borders and countries, reaches every corner of the world. Therefore, literature should pave the way for and strengthen one of the beautiful goals of our life - the kinship of peoples" [28, p. 434]. This raises different issues such as the stagnation of literary criticism, the lack of theater critics' presence in the mainstream media, the inability to find common ground with the opera houses, etc. The classic, knowing all the nuances of the writing profession, reveals the essence of creativity to young writers: "… with the first confident steps and serious works, writers should learn to look at their surroundings, their nation and compatriots with piercing and thoughtful eyes. Knowledge of the native language, recognition of its precious features and its preservation in literary works are the main responsibilities of a writer" [28, p. 480]. The writer considers A. Yeniki and M. Aglyamov to be the authors who faithfully served literature from their very first steps; he expresses his critical remarks on the early stages of M. Dzhalil's and H. Tufan's works, arguing that we should not turn a blind eye to their weak points: "The pre-war period of Dzhalil's work should be considered the product of his time. Tufan's works before and after his imprisonment never served the purpose of sharing the hardships of our nation. His early poetic experiments are full of artificiality, spontaneity and literary samples created only for the sake of gaining experience. The fate of the people, their misery and the compromised future of the nation were never mentioned by Tufan. And for the most part, he remained a poet for other poets, serving as a training ground for authors. Therefore, prisons and camps became a turning point on the creative path of Dzhalil and Tufan. The "Моабит дәфтәре" ("Moabit Notebooks") and the Tufan's prison collections are the peak of their oeuvre. While the poets remained ordinary writers when they were free, their imprisonment led them to spiritual freedom. The circumstance that unified the fates of these poets has not yet been figured out and clarified. We still ignore the fact that Tufan could not break

away from the “leftist” agenda, even after going through prisons and camps” [28, p. 494].

In short, M. Khabutdinova has managed to collect the material describing the spiritual courage of the brave, free-minded writer in one edition. The public has been acquainted with a solid article “Җан авазы” (“The Voice of the Soul”) written to honor the publication of the novel “Тайгак кичү” (“A Slippery Crossing”) by the Tatar writer Ibragim Salakhov who survived Stalin’s prisons and camps. Indeed, every problem that worries A. Gilyazov, no matter how subtle and nuanced it is, finds place in his journalistic articles. Thus, in the article “Имән чикләвеге” (“A Hard Nut to Crack”) included in the collection, the writer noted the fact, which could not be overlooked, although he worshipped the greatness of the poet Hassan Tufan: “How can we explain the fact that Tufan, who served a prison sentence “drinking Laishevsky broth” for so many years, teased Alexander Solzhenitsyn, the great prophet of modern times?? Was he not supposed to recognize Solzhenitsyn right away?!” [28, p. 495].

The eleven memoirs placed in the fifth chapter are the memories of those who recognized and appreciated the courage of the writer during his lifetime. Here, the facts that led to the arrest of Ayaz Gilyazov, the writer’s viewpoint on human being, the fact about “a representative of Tatar prose without God and history” according to M. Galiyev’s words [28, p. 584], and finally, the true face of literature in the “years of conflicting opinions” are revealed in the memoirs of different people including the first President of the Republic of Tatarstan, State Counselor M. Sh. Shaimiev, scholar I. Andreeva, writers G. Akhunov, R. Zaydulla, Sh. Rakipov, R. Valiev, A. Litvin, M. Galiev, T. Galiullin and R. Muhammediev.

The five documents presented in the sixth section include Naki Isanbet’s article of 1961 proving the need to accept Ayaz Gilyazov into the Writers’ Union; a transcript of the discussion of his work “Өч аршин җир” (“Three Arshins of Land”) in the editorial office of the magazine “Дружба народов” (“The Friendship of Peoples”) in Moscow in 1963; a protocol for checking the story “Күзгә-күз” (“Eye-to-eye”) in the Writers’ Union of Tatarstan in 1976; a television speech by Muhammad Magdeev about the writer’s work in 1977; a transcript of a speech by a representative of Hungarian literature, translator Arpad Galgotsi at a conference dedicated to the writer’s work in 2018. These are invaluable materials for the academic community and literature lovers.

I would say that the last chapter of the book is a delayed psalm by Arpad Galgotsi and by many Tatar poets inspired by the oeuvre of the writer who dreamed of seeing Tatar literature on the world stage.

This research and popular collection titled “Ayaz Gilyazov” is a book that will get the attention of Turkic language writers, scattered all over the world, to the national hero’s oeuvre. The literary scholar Milyeusha Khabutdinova managed to fulfill Ayaz Gilyazov’s dream of promoting Tatar national literature on the world stage by compiling the best works about him into one collection and presenting it to the public in the form of a holistic and solid publication.

**References**

1. Gilyazov, A. (2013–2016). *Sailanma əsərlər 6 t.* [Selected Works]. Təz. M. M. Khabutdinova. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)

2. Khabutdinova, M. M. (2017). *Ego pravda, ego molitva* [His Truth, His Prayer]. Gilyazov A. M. Davaite pomolimsya! Pp. 480–490. Kazan', Tatar. kn. izd-vo. (In Russian)

3. Khabutdinova, M. (2016). *Hakaslarda – “Өch arshyn җir”* [“Three Arshins of Land” in Khakass]. Səhnə. No. 5, pp.10–13. (In Tatar)

4. Khabutdinova, M. M. (2020). *“Өch arshyn җir” spektakle kyrgyz səhnəsendə* [“Three Arshins of Land” Performed on the Kyrgyz Stage]. Səhnə. No.12, pp.16–19. (In Tatar)

5. Khabutdinova, M. M. (2009). *Natsional'nyi mif v povesti A. M. Gilyazova “Tri arshina zemli”* [National Myth in A. M. Gilyazov’s Story “Three Arshins of Land”]. Vestnik Tatarskogo gosudarstvennogo gumanitarno-pedagogicheskogo universiteta. No.1 (16), pp. 103–109. (In Russian)

6. Khabutdinova, M. M. (2010). *Sakral'naya toponimika v tvorchestve A. M. Gilyazova* [Sacral Toponymy in A. M. Gilyazov’s Works]. Vestnik Tatarskogo gosudarstvennogo gumanitarno-pedagogicheskogo universiteta. No. 4 (22), pp. 235–240. (In Russian)

7. Khabutdinova, M. M. (2010). *Natsional'nyi khronotop v tvorchestve A. M. Gilyazova* [National Chronotope in A. M. Gilyazov’s Work]. Vestnik Tatarskogo gosudarstvennogo gumanitarno-pedagogicheskogo universiteta. No. 2 (20), pp. 188–196. (In Russian)

8. Khabutdinova, M. M. (2010). *Mifopoehticheskaya osnova rasskaza A. Gilyazova “List'ya mat'-machekhi”* [The Mythopoetic Basis of A. Gilyazov’s Story “The Leaves of Coltsfoot”]. Vestnik Tatarskogo gosudarstvennogo gumanitarno-pedagogicheskogo universiteta. No. 1 (19), pp. 112–117. (In Russian)

9. Khabutdinova, M. M. (2011). *Rol' muzyki v tvorchestve A. Gilyazova* [The Role of Music in A.

Gilyazov's Work]. Vestnik Tatarskogo gosudarstvennogo gumanitarno-pedagogicheskogo universiteta. No.1 (23), pp. 272–278. (In Russian)

10. Khabutdinova, M. M. (2011). *Transformatsiya ideologicheskikh konstruktov v povesti Ayaza Gilyazova "Tri arshina zemli"* (1962) [Transformation of Ideological Constructs in Ayaz Gilyazov's Story "Three Arshins of Land"]. Filologiya i kul'tura. Philology and Culture. No. 2 (24), pp. 238–241. (In Russian)

11. Khabutdinova, M. M. (2011). *Mifopoehticheskaya osnova povesti A. Gilyazova "Kachak"* [The Mythopoetical Basis of A. Gilyazov's "Kachak" ("Fugitive") Novel]. Filologiya i kul'tura. No. 3 (25), pp. 215–220. (In Russian)

12. Khabutdinova, M. M. (2011). *Rol' F. M. Dostoevskogo v formirovanii Ayaza Gilyazova kak pisatelya* [The Role of Fyodor Dostoevsky in the Formation of Ayaz Gilyazov as a Writer]. Vestnik Tatarskogo gosudarstvennogo gumanitarno-pedagogicheskogo universiteta. No. 4 (26), pp. 258–265. (In Russian)

13. Khabutdinova, M. M. (2012). *Topos Kazani v tvorchestve Ayaza Gilyazova* [Topos of Kazan in Ayaz Gilyazov's Work]. Filologiya i kul'tura. Philology and Culture. No. 1 (27), pp. 136–141. (In Russian)

14. Khabutdinova, M. M. (2012). *Iz istorii teksta povesti A.M. Gilyazova "Җomga kөn, kich belən..." ("V pyatnitsu, vecherom...")* (1979) [From the History of A. Gilyazov's "On Friday Evening..."]. Filologiya i kul'tura. Philology and Culture. No. 3 (29), pp. 156–163. (In Russian)

15. Khabutdinova, M. M. (2013). *Lichnost' i tvorchestvo CH.Aitmatova v otsenke tatarskogo pisatelya A. M Gilyazova* [Chingiz Aitmatov's Personality and Creative Work as Seen by the Tatar Writer A. Gilyazov]. Filologiya i kul'tura. Philology and Culture. No. 2 (32), pp. 270–276. (In Russian)

16. Khabutdinova, M. M. (2014). *Zhanrovoe svoeobrazie romana-vospominaniya A. M. Gilyazova "Davaite pomolimsya!"* [Genre Originality of the novel-memoir by A. Gilyazov "Let's Pray!"]. Evropeiskii zhurnal sotsial'nykh nauk. No. 6–1 (45), pp. 207–212. (In Russian)

17. Khabutdinova, M. M. (2014). *Soderzhanie i poehtika obraza deyatelya musul'manskogo dukhovenstva v tvorchestve A. M. Gilyazova (1928–2002)* [The Content and Poetics of the Image of a Muslim Clergy Figure in A. Gilyazov's Works (1928–2002)]. Filologicheskie nauki. Voprosy teorii i praktiki. No. 1–2 (31), pp. 191–195. (In Russian)

18. Khabutdinova, M. M. (2014). *"Vesennie karavany" (1972) A. M. Gilyazova: ot zamysla k voploshcheniyu* ["Spring Caravans" (1972) by A. M. Gilyazov: From Concept to Implementation]. Filologicheskie nauki. Voprosy teorii i praktiki. No. 2–1 (32), pp. 182–186. (In Russian)

19. Khabutdinova, M. M. (2014). *Stsenicheskaya istoriya tragedii A. Gilyazova "Tri arshina zemli" (na primere odnoimennykh spektaklei rezh. F. Ibragimova, M. Salimzyanova)* [Stage History of A. Gilyazov's Tragedy "Three Arshins of Land" (based on the performances of the same name directed by Fail Ibragimov and Marcel Salimzyanov)]. Filologiya i kul'tura. Philology and Culture. No. 1 (35), pp. 215–222. (In Russian)

20. Khabutdinova, M. M. (2015). *Novatorstvo A. M. Gilyazova v povesti "Poseredine"* [Ayaz Gilyazov's Innovations in the Story "In the Middle"]. Kazanskaya nauka. No. 4, pp. 145–147. (In Russian)

21. Khabutdinova, M. M. (2015). *Zhanrovoe svoeobrazie povesti A. M. Gilyazova "Kyzlar yazgan khatlar"* (1969–1970) ("Devich'i pis'ma") [Genre Originality of A. M. Gilyazov's Story "Kyzlar yazgan khatlar" (1969-1970) ("Girls' Letters")]. Filologicheskie nauki. Voprosy teorii i praktiki. No. 11–3 (53), pp. 194–196. (In Russian)

22. Khabutdinova M. M. (2015). *Kontseptsiya tvorcheskoi lichnosti v tvorchestve A. M. Gilyazova* [The Concept of a Creative Personality in Ayaz Gilyazov's Works]. Filologicheskie nauki. Voprosy teorii i praktiki. No. 12–1 (54), pp. 181–183. (In Russian)

23. Nasyrova, A. M., Khabutdinov, A. Yu., Khabutdinova, M. M., Mashakova, A. (2017). *The Role of Prayer Discourse for Karaganda Concentration Camp Image Creation in the Works of the Tatar Writer Ayaz Gilyazov and the Kazakh Poet Halim Zhaylybay*. Astra Salvensis. Tom 5. Vypusk 10. Pp. 201– 207. (In English)

24. Muhametshin, B., Khabutdinova, M., Khabutdinov, A. Yu. (2017). *The Ideological and Artistic Originality in A. Zaripov's Dramatization of the Story "On Friday Night" (1972–1979) by A. Gilyazov*. Astra Salvensis Tom 5. Vypusk 10, pp. 191 – 198. (In English)

25. Faezova, L. R., Khabutdinova, M. M., Gaynyllina G. R., Mashakova A. *The Emigration Theme in Tatar Literature*. Modern Journal of Language Teaching Methods. Tom 8. Vypusk 9, pp. 66 – 71. (In English)

26. Khaybullina, A. A., Zamaletdinov, R. R., Khabutdinova, M. M., Khabutdinov, A. Yu. (2017). *Religious Vocabulary in Ayaz Gilyazov's Novel "Thinner Than Strings, Sharper Than Sword"*. Modern Journal of Language Teaching Methods. Tom 8. Vypusk 11, pp. 399 – 405. (In English)

27. Khabutdinova, M. M. (2018). *Vengerskii sled v tvorchestve A. M. Gilyazova* [The Hungarian Trace in Ayaz Gilyazov's Work]. Filologicheskie nauki v MGIMO. No. 1 (13), pp. 104–112. (In Russian)

28. *"Ayaz Gyjləjev"* (2023) [Ayaz Gilyazov]. Isemle fənni-populyar iyentyk. Təz. 672 b. M. M. Khabutdinova. Kazan, Jyen. (In Tatar)

# «АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ» ИСЕМЛЕ ФӘННИ-ПОПУЛЯР ҖЫЕНТЫККА (ТӨЗ. ХӘБЕТДИНОВА М.М. – КАЗАН: ҖЫЕН, 2023. – 672 Б.) БӘЯЛӘМӘ

**Гөлфия Расил кызы Гайнуллина,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремлевская ур., 18 нче йорт,
gulfiarasilevna@mail.ru.

Рецензиядә «Аяз Гыйләҗев» исемле фәнни-популяр җыентыкка (төз. Хәбетдинова М.М. – Казан: Җыен, 2023. – 672 б.) бәя бирелә. Җыентыкта Татарстан Республикасының халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Аяз Гыйләҗев (1928–2002) турында истәлекләр, әдипнең автобиографик язмалары, тәнкыйди-публицистик мәкаләләре, әңгәмәләре, шәхси архивыннан алынган фоторәсемнәр, документлар, көндәлекләр урын ала. Басма хронологик һәм жанр төрлелеге принципларына нигезләнеп төзелә. Материал сигез бүлеккә тупланып урнаштырыла. Җыентыкның ахырында «Татар кодексы» дигән баш астында Аяз Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога!» әсәренә язучы Рафаэль Сибат биргән бәяләмәнең сөземтәсе урын ала. Миләүшә Хәбетдинованың җыентыкка кереш сүзендә, хатлары, көндәлекләре турындагы гыйльми мәкаләләрендә, Татарстан Республикасының беренче Президенты, Дәүләт киңәшчесе М.Ш. Шәймиев, галимә И. Андреева, язучылар Г. Ахунов, Р. Зәйдулла, Ш. Рәкыйпов, Р. Вәлиев, А. Литвин, М. Галиев, Т. Галиуллин, Р. Мөхәммәдиев истәлекләрендә әдипнең милли сүз сәнгатенә керткән өлеше билгеләнеп барыла, иҗатын тикшерү, бәяләү методлары, анализ юллары һәм фәнни принциплары ассызыклана.

**Төп төшенчәләр**: татар әдәбияты, әдәбият гыйлеме, әдәби тәнкыйть, истәлекләр, көндәлекләр, А. Гыйләҗев.

Татарстанның халык язучысы, ТАССРның Г. Тукай һәм РСФСРның М. Горький исемендәге дәүләт бүләкләре, Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый һәм С. Рәфыйков исемендәге әдәби премияләре иясе, Татарстанның, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Аяз Гыйләҗевнең (1928–2002) әдәби һәм публицистик иҗаты татар әдәбият гыйльмиятенең, тәнкыйтьнең һәрвакыт игътибар үзәгендә булды. Соңгы өч дистә елда язучының күпкатламлы иҗади мирасын өйрәнүгә, дөнья әдәбияты мәйданында танытуга, әсәрләре хакындагы төрле дәвердәге әдәби тәнкыйтьне туплауга, классик иҗатны концептуаль якын килеп бәяләүгә әдәбият галиме Миләүшә Хәбетдинова керткән өлеш бәһаләп бетергесез. Аяз Гыйләҗевнең шәхси архивында эшләү нәтиҗәсендә галимә тарафыннан язучының яңа академик алты томлыгы төзелде [1]. Иҗади мирас рус, инглиз, төрек, венгр, хакас телләрендә дөнья күрде [2], драматургиясе аерым төрки халыкларның сәхнәләрендә беренче тапкыр тәкъдим ителде [3], [4]. Галимә татар әдибенең дөнья әдәбияты үсешенә керткән өлешен нигезләп, күпсанлы гыйльми хезмәтләр бастырды [5] – [26]. Язучы аралашкан дөньякүләм мәгълүм иҗат әһелләре белән элемтә урнаштырып, М. Хәбетдинова венгр әдибе Арпад Галгоцины татар әдәби-мәдәни мохитендә танытты [27]. Сәясәтчеләр, күпсанлы зыялылар, язучының гаиләсе истәлекләрен барлап, фәнни җәмәгатьчелек алдында даими чыгышлар ясап килде.

«Аяз Гыйләҗев» исемле фәнни-популяр җыентык [28] – татар әдәбиятын дөнья әдәбияты мәйданында танытуны гыйльми тормышының кыйбласы иткән галимәнең чираттагы хезмәт җимеше.

Кереш сүзендә М. Хәбетдинова җыентыкны төзү максатын укучыга мөрәҗәгатендә аерымачык белдерә: «А. Гыйләҗев – талантлы әдип кенә түгел, намуслы гомер кичергән милләт хадиме дә. Кадерле укучы! Китапны кулга алуга татарның әдәби мирасына зур өлеш керткән язучыны искә ал, хөрмәтлә, укып ләззәтлән!» [28, 5 б.]

Җыентыкны Аяз Гыйләҗевнең автобиографик язмалары ачып җибәрә. Биредә әдипнең 1972 елдан башлап 2000 елларга кадәрге вакыт аралыгында иҗат ителгән тугыз язмасы туплап бирелгән. 1972 елгы «Үзем турында үзем» язмасында әдип үз иҗатының кыйбласын атый: «Туган иленә, халкына бирелгәнлек, туган теленә сүнмәс мәхәббәт – менә ул язучының үзгәрмәс кыйблалары! Тормыш шартлары, яшәү күренешләре көнләп-сәгатьләп үзгәреп

торса да, бу бөек төшенчәләр мәңгелек, һәм шушы мәңгелеккә тугры кешеләр генә үзгәрешләрне халык белән бергә сиземли алалар» [28, 5 б.]. 1984–1989 еллар аралыгында язылган «Яра» повестеннан алынган «Үзем» бүлеге – җыентыктагы беренче бүлекне йомгаклап килгән кайма – әдипнең сайлаган кыйбласына тугрылыгын дәлиләү өчен урнаштырыла: «Мәңгелек – безнең изге җиребез, зәңгәр планетабыз. Мәңгелек – безнең зәңгәр күгебез, мәңгелек нурлы кояш, ягымлы-ягымлы ай, гомеребезне бизәп, бәйрәм ясап балкыган сансыз-исәпсез йолдызлар. Иделебез, сыгылмалы матур телебез, моңыбыз, Тукай, Сәйдәш... Безнең күңелләргә Бетховен, Шаляпин, Григлар да иркен керә, океан-диңгезләр, елга-дәрьялар, Кавказ-Кырым таулары да сыя, алар да синеке, син – кеше, синең күңелең күпне тели, күпне үз итә ала. Җан диләр, йөрәк диләр, татар халкы шулар уртасына Күңел дигән серле дәрья урнаштырган. Кеше Күңеле күзгә күренми, барлыгы беленми, әмма ул бар. Күңел кеше белән бергә туа, бергә ярала, әле ул буш була, тора-бара тормыш тәҗрибәсе, хисләр, тәэсирләр, мәхәббәт белән байый» [28, 138 б.]. Аяз Гыйләҗев татар әдәбиятын дөнья әдәбиятының аерылгысыз бер канаты итеп күрә, иҗади мирасны милләтне дөньякүләм танытуга йөз тоткан мәрҗән дип күзаллый. Галимә Миләүшә Хәбетдинова җыентыктагы материалны шул концепциягә утырта.

Икенче бүлектә язучының хатлары урын ала. Бүлеккә кереш итеп бирелгән «Хат – сәнгатьнең бер төре ул» исемле мәкаләсендә галимә хатларга әдипнең аерым әһәмият бирүен ассызыклый: «Хатларны саклау үтенече белән әдип якыннарына еш мөрәҗәгать иткән, ләкин, төрле сәбәпләр аркасында, күп кенә язмалар юкка чыккан. Ә инде сакланып калганнары безгә язучының тәрҗемәи хәлен өйрәнергә, шул чорга хас булган сәяси-иҗтимагый вакыйгалар турында фикер тупларга ярдәм итә» [28, 144 б.]. Шунысы да игътибарга лаек: М. Хәбетдинова соңрак А. Гыйләҗевнең эчке халәте төшенкелеккә үзгәрүенә басым ясый, хатлардан китеп, көндәлек жанрына мөрәҗәгать итүен язучының үз сүзләренә таянып нигезли: «Туксан икедә хатларны нык киметтем, хисләрне бүлешерлек, уйларны уртак итәрлек, сер чишеп җиңеләйтерлек адәмнәр калмады. Уйларымны ялгызлар тыкрыгына алып кереп киттем дә караңгы күлгә – «көндәлекләргә» яшердем» [28, 147 б.].

Ике дистәдән артык хатлар әдипнең сөекле тормыш иптәше, гаиләсенә һәм ире сайлаган юлга тугры мөгаллимә Нәкыя Гыймадиева-Гыйләҗевага, хөр фикерле әдипләр, каләмдәшләре Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Туфан Миңнуллин, Шәүкәт Галиев, Якуб Зәнкиев, Нәҗип Әсәнбаевка, «Казан утлары» редакциясенә, тәрҗемәче Искәндәр Гыйззәтуллинга, тәнкыйтьче Мансур Вәлиевкә, милләтпәрвәр шәхесләргә адреслана. Хатларда – әдипнең йөрәгендәге милли гамь, тирән әрнүсызланулары, шул чор әдәби-мәдәни барышына мөнәсәбәтле тәнкыйди фикерләре, бәясе урын алган. Хатларны бер төпләмгә туплау принцибын аңлату өчен язучының 1982 елны М. Вәлиевкә юлланган хаттан өзекне китерү җитә: «Бүгенгедән Тукай, Такташ, Җәлилләр белән янәшә куярлык күпме хәзинәбез калыр? Дөрес, китапларның язмышын, язучыларның көч-куәтен билгеләү хокукы киләчәккә бирелгән, әмма мәсьәләнең болай куелышы да безгә таләпчәнлекне йомшартырга хокук бирми, киресенчә, без әдәбиятыбызның үсеш югарылыгы өчен һәрчак сакта һәм көрәштә булырга бурычлы. Без исә соңгы вакытта таләпчәнлекне бик нык йомшарттык, үзебезнең әдәби мирасыбыз янәшәсенә заман сынауларын уза алмаслыгы бүгеннән үк мәгълүм булган байтак әсәрләрне куярга маташабыз, безгә хәзер Ф. Хөсни дә классик, Г. Минский да классик, гел очраклы кешеләргә бөек гражданинybыз Г. Тукай исемен йөрткән бердәнбер премиябезне бирәбез, мактаулы чуар ярлыклар ябыштырабыз...» [28, 208-209 б.]. Әйтергә кирәк, галимә М. Хәбетдинованың әдип хатларын бәяләгән фәнни хезмәтләрендә иҗади мирасның бу тармагына тулы анализ тәкъдим ителә [28].

Өченче бүлектә А. Гыйләҗевнең көндәлекләреннән өзекләр урын ала. Бүлеккә кереш вазифасын үтәгән «Уйларның төрмәсеннән котылу» ысулы» дип исемләнгән язмада М. Хәбетдинова болай билгеләп үтә: «1992–1997 елларда көндәлек алып бару А. Гыйләҗевнең бурычына, кыйммәтле шәхси актына әверелә. Алга таба, авырып китү сәбәпле, әдип язмаларны мөстәкыйль рәвештә теркәп бара алмый башлый, һәм бу эш авырая» [28, 208–209 б.]. Бүлекнең башлам өлешендә галимә А. Гыйләҗевнең 1980 елны язылып, 2005 елны дөнья күргән «Мин шулай уйлыйм» мәкаләсен урнаштыра. Биредә 1960–1980 еллар әдәби барышында язучыны борчыган мәсьәләләр кабыргасы белән куела, туган

әдәбиятларына киңрәк масштабта танылырга юл куймаган татар зыялылары, шул чордагы әдәби мохитнең чын милләтпәрвәр шәхеснең рухын җимерүгә йөз тотканлыгы фаш ителә: «Ничек исән калынган, дигәндә, Мәскәү коткарды. Мәскәү руслары, Мәскәү яһүдләре аралап калган, алар алга атларга көч биргән, дәрт өстәгән» [28, 343 б.]. 1992 елгы көндәлекләрдән өзекләрдә үзен «җирдәге хаклык өчен көрәшергә бурычлы санаган» [28, 352 б.] әдипнең туксанынчы елларда урнашкан иҗтимагый шартларда, татар язучыларының рухи кыйблалары түбәнәйгәннән-түбәнәя барган хәлдә әдәбимәдәни барышның киләчәге өчен борчылуы үзәккә алынып тәкъдим ителә.

Җыентыкның дүртенче бүлегендә Аяз Гыйләҗевның сигез сандагы әдәби-тәнкыйть мәкаләсе урнаштырылган. Биредә иҗат кыйбласына тугры каләм иясенең әдәбиятның «халык күңеленә үтеп керү» [28, 433 б.] тиешлеге принцибыннан чыгып, чордашларының иҗатларына тәнкыйди бәясе урын ала. Татар әдәбияты, һичшиксез, дөньякүләм яңгыраш алырга хаклы да, тиеш тә: «Әдәбият, башка бик күп бурычлары белән беррәттән, төрле-төрле халыкларны бер-берсенә якынайта, таныштыра, аларда дуслык, туганлык хисләре тәрбияли. Бу – аның иң изге бурычларының берсе. Һәм иң олы бурычларының берсе, дип тә өстәр идем мин. Әдәбиятның көчен бу өлкәдә һич бәяләп бетерерлек түгел. Әдәбият – шагыйрьләр, язучылар сүзе – илләр, чикләр аша үтә, дөньяның барлык почмакларына барып җитә. Димәк, әдәбият тормышыбызның гүзәл бер максатын – халыклар туганлыгына юл ачарга, аны ныгытырга тиеш» [28, 434 б.]. Бу җәһәттән, әдәби тәнкыйтьнең торгынлыгы, театр тәнкыйтьчеләренең үзәк матбугатка сирәк чыгулары, опера театры белән уртак тел таба алмау һ.б. күпсанлы проблемалар кабыргасы белән куела. Язучы һөнәренең бөтен нечкәлекләрен тоеп эш иткән классик әдип яшь язучыларга иҗатның асыл серен уйдырып сала: «...язучы үзенең беренче ныклы адымнарыннан ук, беренче җитди сүзеннән үк тирә-ягына, халкына, җирдәшләренә, милләттәшләренә үткен, уйчан күз белән карарга өйрәнсен. Чөнки туган телне белү, аның кадерле җәүһәрләрен барлау, әсәрләрендә аны туплау, ныгытып калдыру – язучының төп бурычларыннан берсе» [28, 480 б.]. Беренче адымнарыннан ук әдәбиятка намуслы хезмәт иткән әдипләр рәтенә язучы Ә. Еники, М. Әгъләмовларны кертүен әйтә, М. Җәлил, Х. Туфаннар иҗатларының башлангыч чорларына мөнәсәбәтле тәнкыйди фикерләрен җиткерә, күз йомарга кирәкмәгәнлекне аерымачык әйтә: «Җәлил иҗатының сугышка кадәрге чоры үз заманының җимеше дип бәяләнергә тиеш. Туфанның төрмәгә ябылганчы һәм аннан соңгы иҗат үрнәкләре бер чакта да халкыбызның авыр язмышын ачуга хезмәт итмәделәр. Аның беренче шигъри тәҗрибәләрендә ясалмалык, кыланчыклык һәм тәҗрибә хакына гына ясалган үрнәкләр тулып ята. Халык язмышы, аның ачы нужасы, милләтнең киләчәге кыл өстенә куелуы Туфан иҗатында урын ала алмады. Һәм ул күпчелек очракта шагыйрьләр шагыйре, әдәбиятчыларның тәҗрибә урыны булып кала килде. Димәк, төрмә-лагерьлар Җәлил, Туфан иҗатында гаять зур борылыш ясадылар, «Моабит дәфтәре» һәм Туфанның төрмә циклы алар иҗатының таҗы булып калды. Шагыйрьләр иркенлек иҗатында гадәти әдипләр булып калсалар, төрмә кысасы аларны рухи иркенлеккә чыгарды. Бу – шагыйрьләр язмышларын янәшә китергән хәл дә әлегәчә билгеләнмәгән, тулысынча ачыкланмаган. Туфанның төрмә-лагерь юлларын үтеп тә һаман «суллык» кизүеннән аерыла алмавын без һаман читләтеп үтәбез...» [28, 494 б.]

Җыеп әйткәндә, галимә М. Хәбетдинова кыю, хөр фикерле әдипнең рухи батырлыгын тасвирлаган материалның сөземтәсен бер җыентыкка туплый. Җәмәгатьчелеккә Сталинның төрмә-лагерьларын үз башыннан уткәргән татар әдибенең Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү» романы басылуга дөнья күргән «Җан авазы» исемле саллы мәкаләсе тәкъдим ителә. Чынлап та, А. Гыйләҗевны борчыган һәр проблема, нинди генә нечкә һәм четерекле булуына карамастан, публицистик язмаларында урын ала. Әйтик, җыентыктагы «Имән чикләвеге» мәкаләсендә әдип шагыйрь Хәсән Туфанның олылыгы алдында баш исә дә, күрми калырга ярамый торган хакыйкатьне билгеләп үтә: «Төрмә юлларын үткән, ничәмә-ничә ел «лаеш шулпасы эчкән» Туфанның чорыбызның бөек пәйгамбәре Александр Исаевич Солженицынга кизәнүен ни белән аңлатырга? Ул Солженицынны беренче сулышыннан ук танып алырга тиеш иде ләбаса?!» [28, 495 б.]

Бишенче бүлеккә урнаштырылган унбер хатирә – әдипнең рухи батырлыгын ул яшәгән дәвердә үк таныган һәм бәяләгән шәхесләрнең истәлекләре. Биредә Татарстан Республикасының беренче Президенты, Дәүләт киңәшчесе М.Ш. Шәймиев, галимә И. Андреева, язучылар Г. Ахунов, Р. Зәйдулла, Ш. Рәкыйпов, Р. Вәлиев, А. Литвин, М. Галиев, Т. Галиуллин, Р. Мөхәммәдиев истәлекләрендә Аяз Гыйләҗевның кулга алынуына сәбәп булган фактлар, әдипнең, М. Галиев теле белән әйткәндә, «алласыз һәм тарихсыз татар прозасы вәкиле» [28, 584 б.] булуга мөнәсәбәте, ниһаять, «каршылыклы фикерләрнең нык чәкәләшкән еллары»ндагы [28, 563 б.] әдәбиятның чын йөзе ачыла.

Алтынчы бүлектә тәкъдим ителгән биш документ – Нәкый Исәнбәтнең 1961 елны Аяз Гыйләҗевны Язучылар берлегенә алу тиешлеген дәлилләп язган мәкаләсе, 1963 елны Мәскәүдә «Дружба народов» журналы редакциясендә «Өч аршин җир» әсәре турында фикер алышу стенограммасы, 1976 елда Татарстан Язучылар берлегендә «Күзгә-күз» повестен тикшерү беркетмәсе, Мөхәммәт Мәһдиевнең әдип иҗаты хакындагы 1977 елгы телевизион чыгышы, венгр әдәбияты вәкиле, тәрҗемәче Арпад Галгоциның 2018 елда әдип иҗатына багышланган конференциядәге чыгышы стенограммалары фәнни җәмәгатьчелек һәм әдәбият сөючеләр өчен бәһаләп бетергесез кыйммәтле материал.

Китапның соңгы бүлеге – татар әдәбиятын дөнья аренасында күрергә хыялланган әдипнең иҗади мирасы белән рухланып дөньяга килгән Арпад Галгоци һәм татар шагыйрьләренең иҗат җимешләре, соңарган мәдхиясе, дияр идем.

«Аяз Гыйләҗев» дип исемләнгән әлеге фәнни-популяр җыентык – милләт хадименең иҗади мирасына бөтен дөньяга сибелгән төрки телле әдәбиятчыларның игътибарын җәлеп итәчәк китап. Әдәбият галиме Миләүшә Хәбетдинова Аяз Гыйләҗевның васыятен – милли әдәбиятыбызны дөнья аренасында таныту хыялын тормышка ашыру өчен күпер салып, иҗади мирасның каймагын бер җыентыкка туплап, киң җәмәгатьчелеккә бөтенлекле, саллы хезмәт рәвешендә тәкъдим итүгә ирешкән.

**Әдәбият**

1. Гыйләҗев А. Сайланма әсәрләр 6 т. / Төз. М.М. Хәбетдинова. Казан: Татар. кит. нәшр, 2013–2016.

2. Хабутдинова М.М. Его правда, его молитва // Гилязов А.М. Давайте помолимся! Казань: Татар. кн. изд-во, 2017. С. 480–490.

3. Хәбетдинова М. Хакасларда – «Өч аршын җир» // Сәхнә. 2016. №5. Б.10–13.

4. Хәбетдинова М.М. «Өч аршын җир» спектакле кыргыз сәхнәсендә // Сәхнә. 2020. №12. Б.16–19.

5. Хабутдинова М.М. Национальный миф в повести А.М. Гилязова «Три аршина земли» // Вестник Татарского государственного гуманитарно-педагогического университета. 2009. № 1 (16). С. 103–109.

6. Хабутдинова М.М. Сакральная топонимика в творчестве А.М. Гилязова // Вестник Татарского государственного гуманитарно-педагогического университета. 2010. № 4 (22). С. 235–240.

7. Хабутдинова М.М. Национальный хронотоп в творчестве А.М. Гилязова // Вестник Татарского государственного гуманитарно-педагогического университета. 2010. № 2 (20). С. 188–196.

8. Хабутдинова М.М. Мифопоэтическая основа рассказа А. Гилязова «Листья мать-мачехи» // Вестник Татарского государственного гуманитарно-педагогического университета. 2010. № 1 (19). С. 112–117.

9. Хабутдинова М.М. Роль музыки в творчестве А. Гилязова // Вестник Татарского государственного гуманитарно-педагогического университета. 2011. № 1 (23). С. 272–278.

10. Хабутдинова М.М. Трансформация идеологических конструктов в повести Аяза Гилязова «Три аршина земли» (1962) // Филология и культура. Philology and Culture. 2011. № 2 (24). С. 238–241.

11. Хабутдинова М.М. Мифопоэтическая основа повести А. Гилязова «Качак» // Филология и культура. 2011. № 3 (25). С. 215–220.

12. Хабутдинова М.М. Роль Ф.М. Достоевского в формировании Аяза Гилязова как писателя // Вестник Татарского государственного гуманитарно-педагогического университета. 2011. №4 (26). С.258–265.

13. Хабутдинова М.М. Топос Казани в творчестве Аяза Гилязова // Филология и культура. Philology and Culture. 2012. № 1 (27). С. 136–141.

14. Хабутдинова М.М. Из истории текста повести А.М. Гилязова «Җомга көн, кич белән...» (“В пятницу, вечером...”) (1979) // Филология и культура. Philology and Culture. 2012. № 3 (29). С. 156–163.

15. Хабутдинова М.М. Личность и творчество Ч.Айтматова в оценке татарского писателя А.М Гилязова // Филология и культура. Philology and Culture. 2013. № 2 (32). С. 270–276.

16. Хабутдинова М.М. Жанровое своеобразие романа-воспоминания А.М. Гилязова «Давайте помолимся!» // Европейский журнал социальных наук. 2014. № 6-1 (45). С. 207–212.

17. Хабутдинова М.М. Содержание и поэтика образа деятеля мусульманского духовенства в творчестве А.М. Гилязова (1928-2002) // Филологи-

ческие науки. Вопросы теории и практики. 2014. № 1–2 (31). С. 191–195.

18. Хабутдинова М.М. «Весенние караваны» (1972) А.М. Гилязова от замысла к воплощению // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2014. № 2–1 (32). С. 182–186.

19. Хабутдинова М.М. Сценическая история трагедии А. Гилязова «Три аршина земли» (на примере одноименных спектаклей реж. Ф. Ибрагимова, М.Салимзянова) // Филология и культура. Philology and Culture.2014. № 1 (35). С. 215–222.

20. Хабутдинова М.М. Новаторство А.М. Гилязова в повести «Посередине» // Казанская наука. 2015. № 4. С. 145–147.

21. Хабутдинова М.М. Жанровое своеобразие повести А.М. Гилязова «Кызлар язган хатлар» (1969-1970) («Девичьи письма») // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2015. № 11–3 (53). С. 194–196.

22. Хабутдинова М.М. Концепция творческой личности в творчестве А.М. Гилязова // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2015. № 12-1 (54). С. 181–183.

23. Nasyrova, A.M., Khabutdinov, A.J., Khabutdinova, M.M., Mashakova, A. // The role of prayer discourse for karaganda concentration camp image creation in the works of Tatar writer Ayaz Gilyazov and the Kazakh poet Halim ZhaylybayAstra Salvensis. Том: 5. Выпуск: 10. P. 201–207.

24. Muhametshin, B., Khabutdinova, M., Khabutdinov, A.J. The ideological and artistic originality in the dramatization of the story ""on friday night"" (1972-1979) by Gilyazova A. M., made by A. Zaripov // Astra Salvensis Том: 5. Выпуск: 10. P. 191–198.

25. Faezova, L.R.; Khabutdinova, M.M.; Gaynyllina G.R.; Mashakova A. The Emigration Theme In Tatar Literature // MODERN JOURNAL OF LANGUAGE TEACHING METHODS Том: 8, Выпуск: 9, P. 66–71.

26. Khaybullina, A.A.; Zamaletdinov, R.R.; Khabutdinova, M.M.; Khabutdinov, A.J. Religious Vocabulary In Ayaz Gilyazov'S NOVEL Thinner Than Strings, Sharper Than Sword // MODERN JOURNAL OF LANGUAGE TEACHING METHODS Том: 8. Выпуск: 11. P. 399–405.

27. Хабутдинова М.М. Венгерский след в творчестве А.М. Гилязова // Филологические науки в МГИМО. 2018. № 1 (13). С. 104–112.

28. «Аяз Гыйләҗев»: исемле фәнни-популяр җыентык / төз. М.М. Хәбетдинова М.М. Казан: Җыен, 2023. 672 б.

---

# РЕЦЕНЗИЯ НА НАУЧНО-ПОПУЛЯРНЫЙ СБОРНИК «АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ» (СОСТ. ХАБУТДИНОВА М.М. – КАЗАН: ҖЫЕН, 2023. – 672 Б.)

**Гөлфия Расил кызы Гайнуллина,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
gulfiarasilevna@mail.ru.

В рецензии дается оценка научно-популярному сборнику «Аяз Гыйләҗев» (сост. Хабетдинова М.М. – Казан: Җыен, 2023. – 672 б.). В книгу вошли воспоминания, автобиографические произведения, критические, публицистические статьи, интервью с народным писателем РТ, лауреатом Государственной премии РТ им. Г. Тукая Аязом Гилязовым (1928–2002), хранящиеся в его личном архиве фотографии, документы. Материалы размещены по хронологии и исходя из жанрового разнообразия. В конце книги размещен «Татарский кодекс», взятый из рецензии Рафаэля Сибата на роман-воспоминание Аяза Гилязова «Давайте помолимся!»; в предисловии, научных статьях Милеуши Хабутдиновой о жанровом своеобразии писем и дневников писателя, в воспоминаниях первого президента РТ, Государственного советника РТ М.Ш. Шаймиева, литературоведа И. Андреевой, писателей Г. Ахунова, Р. Зайдуллы, Ш. Ракипова, Р. Валиева, А. Литвина, М. Галиева, Т. Галиуллина, Р. Мухаммадиева раскрывается вклад А.М. Гилязова в развитие национальной культуры, татарской литературы.

**Ключевые слова:** татарская литература, татарское литературоведение, литературная критика, воспоминания, дневники, А. Гилязов